

Быел миллəтебезнен боек улы – татар əдəбияты классигы, шагыйрь, публицист, яна заман татар əдəбиятына һəм əдəби теленə нигез салучы Габдулла Тукайнын (1886-1913) тууына 131 ел тула. Халык шагыйре Габдулла Тукай доньяга килгəн(26) һəм хушлашкан апрель(15) аенда. Халык аны олылый,боекли,инде ничə буын аны онытмый.
Һəр елнын апрелендə Мордовиянен барлык татар мəктəплəрендə Габдулла Тукайга багышлап торле чаралар vткəрелеп килə. Шулай, Торбеево районы Татар Йонə гомуми топ белем бирv мəктəбе укытучысы, завучы Альфия Мəхмvт кызы Агишева ел саен Тукаебызга багышлап стена газетасы чыгара, быел чыгарып Туган тел кабинетына элгəн инде.       Тагы дəреслəрдə аерым тема буларак, Габдулла Тукайнын тормыш һəм ижат юлын тирəнтен ойрəнv максаты белəн, укучылар белəн бергə торле чыганакларга таянып, əнгəмəлəр алып бара. Ө Рузаевка районы Татар Пешлə гомуми урта белем бирv мəктəбе укытучысы Сания Спартак кызы Саляева 5-6 сыйныфлар арасында Г.Тукайга багышланган КВН Габдулла Тукайнын туган конендə vткəрергə планлаштыра. Дубенка районы Кочкурово урта мəктəбендə «Туган тел» атналыгы кысаларында, Альфия Кетдюс кызы Узбякова укучылары белəн бергə, торле чаралар vткəрvе һəм планнары турында сойлəде:
- Безнен мəктəптə һəр ел апрельдə «Туган тел» айлыгы vткəрелə.  Шул айлык кысаларында мин башлангыч һəм 5 нче сыйныф укучылары



арасында «И туган тел, и матур тел» дип аталган кичə vткəреп килəм; быел vткəрдем

инде. Укучылар бик матур иттереп шигырьләр сойләделәр. Аннары ике командага бvленеп торле биремнәр vтәделәр, сорауларга жавап бирделәр. Эшлекле уен укучыларга ошады, алар бик актив катнаштылар. Һәр укучы vз командасы очен тырышты. Сонга  Габдулла Тукайнын «Эш беткәч уйнарга ярый» шигыре буенча тошерелгән мультфильмны торле милләт балалары белән бергә карадык. Татарча белмәгән  әрзә милләтле укучылар да бу әсәрнен мәгънәсен анладылар һәм сорауларга жавап бирделәр. 26 нчы апрельдә 8-11 нче сыйныф укучылары белән  Г.Тукай ижаты буенча «Йолдызлы сәгать» vткәрергә жыенабыз.




Кадошкино районы Латышовка авылы мәктәбендә матур иттереп «Туган тел» конен, барлык телләргә багышлап, район кvләмендә vткәргәннәр. Татар мәктәбендә педагоглар рус, мукшы, татар телләре vсеше турында сойләгәннәр, татар телендә мавыктыргыч чара vткәргәннәр, йомгаклау олешендә пәрәмчәләр, бәлешләр белән бергәләп vләнле татар чәе эчкәннәр. Очрашу нәтижәле vткән. Фикере белән Светлана Равиль кызы Поташова, Латышовка урта мәктәбе укытучысы, уртаклашты:

- Мордовия жирендә барлык халык дус яши. Менә мероприятиябезне дә уртак иттек: бер-беребезне мәдәни яктан да баеттык. Шулай, 17 апрельдә Латышовка гомуми урта белем бирv мәктәбебездә Латышовка, Адашево, Большие Поляны, Кадошкино мәктәпләре укучылары шигырьләр яттан сойләделәр, матур иттереп биеделәр, жырларны туган рус, мукшы, татар телләрендә башкардылар. Габдулла Тукай шигырьләрен Латышовка, Большие Поляны-Иса мәктәпләре укучылары яттан сәнгатьле иттереп сойләделәр. Докладны Вяльшина Галина Петровна укыды, Айсина Римма Равиль кызы белән Кандралеева Рузалия Рәстәм кызы һәм мин – чаранын эчтәлеге очен жаваплы идек. Файдалы чара бергәләп чәй эчv белән тәмамланды.

Мордовиянен барлык татар мәктәп-ләрендә, гадәттәгечә, Тукай туган ко-нендә Шигърият бәйрәмнәре уза.

**Наилә Насырова**